СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.07.2021 г.Зеленодольск № 52

2009 елның 23 декабрендәге 184 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән (Зеленодольск шәһәре Советының 2012 елның 16 мартындагы 96 номерлы һәм 2015 елның 23 декабрендәге 39 номерлы карарларында кертелгән үзгәрешләре белән) расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1. 2009 елның 23 декабрендәге 184 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән (Зеленодольск шәһәре Советының 2012 елның 16 мартындагы 96 номерлы һәм 2015 елның 23 декабрендәге 39 номерлы карарларында кертелгән үзгәрешләре белән) расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итәргә мөмкин.»;

1.2. 14 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) инициатив проект турында фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет Рәисе** **М. П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА * ИНН 1648017449 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ